ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

*БУА*
*РАЙОН СОВЕТЫ*

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

*БУИНСКИЙ*
*РАЙОННЫЙ СОВЕТ*

КАРАР
РЕШЕНИЕ

9 декабрь 2010 ел № 8-4

«Буа муниципаль районының мактаулы гражданы» исеме турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»

Буа район Советы карар кабул итте:

1. Буа район Советының 2006 елның 27 июнендәге 53-9 номерлы карары белән расланган «Буа муниципаль районының мактаулы гражданы» исеме турында нигезләмәгә (2008 елның 23 октябрендәге 14-31 номерлы һәм 2010 елның 16 августындагы 11-45 номерлы Буа район Советы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 бүлекнең 1.2 пунктчасында «Шәһәр көнен бәйрәм итү алдыннан» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 бүлекнең 2.5 пунктчасында «ел саен Шәһәр көнен бәйрәм итүгә кадәр 4 айдан да соңга калмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 2.7 пунктчада «Шәһәр көнен бәйрәм итүгә бер айдан да соңга калмыйча, елга бер тапкыр» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы башлыгы урынбасары В.Н. Егоровка йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Буа район Советы рәисе Р.Х. Абузяров